ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында ветеринария эше турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында ветеринария эше турында” 1993 елның 13 июлендәге 1934-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 19 июлендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 6 – 7; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 10 (8); 2003, № 5; 2005, № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 1; 2011, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда:

а) 2 өлешнең бишенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

б) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендәге вәкаләтле органы җитәкчесе бер үк вакытта Татарстан Республикасының баш дәүләт ветеринария инспекторы булып тора.”;

2) 6 статьяның 12 пунктында “дәүләт” сүзе алдыннан “региональ” сүзен өстәргә;

3) 22 статьяның 1 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2016 елның 9 июле
№ 61-ТРЗ